

Ельник районы Ильич исемендәге ачык чикле момкинчелекле жәмгыять-челегендә унтугыз ел машина йортvче булып хезмәт итә Наиль Рәхим улы Утешев.
Балачактан ук ул машина руле турында хыяллана. Шоферлыкка белем алгач, бераз эшләп олгерә һәм Советлар Армиясе сафына хезмәткә алына. 1978 - 1980 елларда Наиль Рәхим улы Утешев Германиядә хәрби хезмәттә була. Алган профессиясенә тугрылыклы булып, водитель буларак, минометлар батареясендәге тягачны йортә. Хәрби хезмәтне лаеклы башкарып кайта. Чит илләрдә хезмәт итvчеләрнен армиядә алган тәжрибәсе һәм тәртибе гомерлеккә кала, диләр. Язма героебызнын да тормыш кредосында шулар була: олы тәжрибә һәм бар жирдә тәртип. Нәтижәдә, машина руле артында тормышынын кvп олешен, кырык елын vткәрә Наиль Рәхим улы Утешев. Армиядән кайткач, 1981нче елны, Ельник районындагы «Сельхозтехника»га эшкә урнаша, «Урал» машинасын йортә. Аннары ун ел, реорганизациягә кадәр, «50 лет СССР» колхозы шоферы була. Менә инде ике дистә елга кадәр, 2000 елдан, Наиль Рәхим улы – Ильич исемен йорткән ОООнын водителе. Ул «ГАЗ-53»тән бернинди авырлыксыз зур һәм кочле «КамАЗ»га кvчеп утыра. Универсаль машина йортvче хужалык эчендә һәм еракларга торле груз кvчерv белән шогыльләнә. Уныш жыйган вакытта кыр белән ашлык амбарын иртәнге таннан кояш батканчыга кадәр ничәмә-ничә тапкыр vтә; машинасында ашлык ташый, мал-туарга кышка азык әзерли. Тырыш хезмәте очен Наиль Рәхим улы Утешев Мордовия авыл хужалыгы министрлыгы Рәхмәте (Благодарность Министерства сельского хозяйства РМ) белән бvләкләнә. Авыр, жаваплы ул шофер булу, әмма Наиль Рәхим улы сайлаган эшен яратып башкара.

**Н.Хәлил**